РӘХӘТ ҖӘЙ
Быел Татарстан лагерьларында 155 меңгә якын бала ял иткән

> 2

УКУЧЫ СҮЗЕ
«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары

> 3

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Үз йортында һәркем үзе тәртип урнаштырырга тиеш»

> 4

ЯШЬЛЕК УЗМАГАН
«Көмеш» волонтер тормышны игелекле эшләргә багышларга киңәш итә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 142 (28915) | Чәршәмбе | 28 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КЫСАДАН ЧЫГУ

ЯШҮСМЕРЛӘРНЕҢ КЫЗЫКСЫНУЛАРЫ ҺӘРВАКЫТТА ДА ХӘЕРЛЕГӘ ИЛТМИ

Тыелганы – татлырак, куркыныч тудырганы – кызыграк. Бигрәк тә үсеп килгән буын өчен. Моңа өстәп башкалардан үзгәрәк, кыюрак, кирерәк булып та күренәсе килә. Маҗараларга омтылуның нәтиҗәсен уйлап бетерү генә юк инде ул... Куркыныч тоелган юлдан саклыйм дисәң, җәнҗал кубарга мөмкин. Балага да, ата-анага да, җәмгыять өчен дә сорау бер: нишләргә? Кыса белән ирек чиге кайда югала? Үсеп килгән буынга ни җитми?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Күңел халәте

Исемен күрсәтми генә аралашкан әңгәмәдәшебезгә хәзер 25 яшь. Район мәктәбендә белем алган, соңрак Казанда университет бетергән. Хәзер шәхси финанс компаниясендә белгеч булып эшли. Аның да яшүсмер һәм яшьлек чорында сәерлекләре җитәрлек булган.

– Мәктәптә укыган чорда малайларча киенеп йөри башладым. Кыз буларак үземне күрсәтәсем килмәдеме, бәлки, нәфислегем юк дип уйлаганмынмы – белмим. Гел чалбардан, кедадан йөрдем. Дус кызларым да булды, әмма малайлар белән уртак телне табу күпкә җиңелрәк иде. Итәк кию минем җенемне котырта иде. Малайлар сыман галстук та тагып йөрдем әле, – дип искә алды ул. – Шунысы да бар: мин имин гаиләдә үстем, дип әйтә алмыйм. Әйе, тулы гаилә иде ул, әби-бабайлы, әти-әниле, туганнар күп. Әмма бабай да, әти дә берне «тотып куярга» яратты. Шул рәвешле өйдә тавыш-гауга куба иде. Яшүсмер булып җитлеккән чорда үз-үземне аңлы рәвештә очлы нәрсәләр белән кисә, яралый башладым. Бу күренеш селфхарм дип атала икән. Ул чакта мин аны аерым бер агым дип, шуның тарафдары булам дип башкармагандыр да инде. Тәнне яралау күңелдәге давылны басарга ярдәм итә иде. Әлбәттә, ул яралар тәннең кеше күрерлек өлешләренә ясалмады. Кул, беләк, аяклар кан белән сыкрап тора иде инде. Хәзер искә алу да бер сәер. Мин шуны аңладым: күңел халәтен кемгә һәм ничек аңлатырга белмәгәнмен, шуңа шулай кыланганмын.

Нишләргә?

Руфинг, селфхарм, зацепинг… Яңа заман алып килгән һәм яшьләр кызыгып кушылган агымнарның берничәсе генә әле ул. Селфхарм турында әйттек инде. Руфинг дигәненә биеклек яратканнар кушыла. Бу – бина түбәләренә, каланчаларга, күперләргә, күпкатлы йортларга менү, кул-аяк белән асылынып тору кебек күренешләрдән гыйбарәт юнәлеш. Зацепинг дигәне шулай ук куркыныч: бу агымны үз итүчеләр хәрәкәттә булган поезд вагоннарына, аның тоткычларына, баскычларына тотынып, аяклары белән асылынып йөри.

Соңгы арада баш калкытканы – «Вертер синдромы» дигән агым. Җәмгыятьне тетрәндергән, гаҗәпкә калдырган үтерү, көч куллану очракларыннан соң шушы золымны кылган кешегә охшарга тырышу, аны үрнәк итеп кую омтылышы бу. Кызганыч, шушы елларда андыйларны да күп күрдек…

Яшүсмерләрнең деструктив үз-үзләрен тотышының сәбәбен социаль челтәрләр, компьютер уеннарына гына сылтап калдыру дөрес булмас. Психологлар сәбәпләрнең тирәндәрәк булуын ассызыклый. Иң элек бу – гаилә, мәктәп яисә аралашу даирәсендәге мөнәсәбәтләрнең җимерелүе. Аннан өлкәннәрнең игътибарыннан мәхрүм калуны да телгә алырга була. Якын саналган кешеләр белән низагка керү, мәктәптәге (шул исәптән укытучылар белән дә!) ыгы-зыгылар да үсмер аңына тәэсир итми калмый. Җавапсыз мәхәббәт, кыйбла таба алмау, яшәү мәгънәсен күрмәү, кыскасы, яшьли яшәп тую да сәбәпләр исемлеген тулыландыра. Бертөрле тормыш рәвеше дә үсмернең үз-үзен тотышына йогынты ясый.

Психология фәннәре магистры, практик психолог Чулпан Нигъмәтҗанованың ата-аналарга балаларын үз-үзләренә йомылудан һәм куркыныч төркемнәргә кушылудан саклау буенча кайбер киңәшләре бар.

– Криминал һәм деструктив юнәлешләргә бәйле мәгълүмат күп. Яшүсмерләр мондый мәгълүматны бик тиз йотып ала. Ата-аналарга балалары белән күбрәк һәм ешрак сөйләшергә кирәк. Тавыш күтәрергә, кем беләндер чагыштырырга, шелтәләргә түгел! Сөйләшергә! Сораулар бирергә, ярдәм кирәкмиме, дип сорарга. Хәзерге балалар бик үпкәчел. Бу куркыныч! Аннан, шәхесне формалаштыруда фильм, китап, тышкы факторлар да йогынты ясый. Кагыйдәләрне санга сукмый торган эчтәлектәгеләр яшь аңга илһам өстәргә мөмкин.

Психология фәннәре кандидаты Вера Герасимова исә аралашканда бала белән ата-ана арасындагы элемтә дөрес корылырга тиеш дигән фикердә тора.

– Ата-ана баланы йә артыгы белән чикли, таләп итә, йә бик күп нәрсәгә ирек куя. Тулы ирек тә, артыгы белән кайгырту да баланың кыйммәтләр системасына, тотышына йогынты ясый, җимерә ала, – ди ул. – Баланы артык яратудан да файда юк. Кайбер үсмерләр белән сөйләшкәндә: «Син гаиләдә кем?» – дип сорагач, «Мин – бала», – диләр. Ә бит ул, кыз һәм бала булу арасында аерма бар. Ул һәм кызның бурычлары, хокуклары була. Ә балага исә барысы да ярый һәм рөхсәт. Үзебезнең артык мәхәббәтебез белән без «кулланучы шәхес» тәрбиялибез. Ул үз тормышын да, бүтәннәрнекен дә саклый, гамәлләре өчен җаваплылык тоя. Деструктив юнәлешләргә кушылуын теләмәсәгез, бала белән аралашырга кирәк. Ул кирәккә генә дигән аралашу булырга тиеш түгел, шунысы мөһим.

Һәр ялтыраган алтын булмаган кебек үк, һәр баланың да үз-үзен тотышы деструктив була дигән сүз түгел. Кайчагында тормыш шундый үрнәкләр күрсәтә: тел шартлатып, гаҗәпкә калып озак йөрисең әле. Төп нәтиҗә дә шул: игътибар һәм аралашу һәркемгә кирәк!

Ахыры 2 нче биттә >

Иминлек чаралары көчәя

Ижау мәктәбендәге атыштан соң Татарстан уку йортларында иминлек чаралары көчәячәк. Хәзер барлык балалар бакчаларында, мәктәпләр һәм көллиятләрдә хәтәр турында кисәтү төймәләре, видеокүзәтү, керү-чыгу системалары, шулай ук сак хезмәткәрләренең эше тикшерелә. Мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәренә караганда, муниципалитетларның мәгариф бүлекләре һәм идарәләре җитәкчеләре белән киңәшмәдә шундый карар кабул ителгән. Уку йортлары хезмәткәрләре белән инструктажлар үткәрелгән, җаваплы кешеләр куркыныч янау очрагында гамәлләр эзлеклелегенә өйрәтелгән.

Моннан тыш республикада психологик ярдәм алу өчен «кайнар линия» телефоны эшли. Ата-аналар һәм балалар психологик ярдәм хезмәтенә бушлай шалтыратып (+7(843) 294-95-70), мәктәпләрнең иминлеге буенча үзләрен борчыган сорауларга җавап табарга мөмкин. Министрлыкта белдерелгәнчә, уку йортларында иминлекне тәэмин итүдә кимчелекләр ачыкланганда кичекмәстән чаралар күреләчәк.

Соңгы мәгълүматларга караганда, Ижау шәһәренең 88 нче мәктәбендәге атышта 17 кеше, шуларның 11е – бала, һәлак булган. Зыян күрүчеләр саны 25кә (23 бала һәм 2 өлкән кеше) җиткән. Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко әйтүенчә, аларның өчесе – чиктән тыш авыр хәлдә. Татарстан, зыян күрүчеләргә ярдәм итү йөзеннән, күрше республикага нейрохирурглар, анестезиолог, реаниматолог, травматолог, психиатр, психологлар – барлыгы 18 белгеч җибәрелгән.

Нәниләргә – бакчалар

Быел Татарстанда 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге сабыйларның 99,97 процентын балалар бакчаларына урнаштыруга ирешелгән. Ләкин, Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә белем бирү бүлеге җитәкчесе Йолдыз Хисамиева әйтүенчә, бу җәһәттән кыенлык кичерүчеләр дә юк түгел әле. Болар – Питрәч районының «Царево» һәм Көек бистәләрендә яшәүчеләр. Лаеш районында бик күп торак төзелә, анда да сабыйларны бакчаларга урнаштыруда кыенлыклар бар. Шуңа күрә Казанга йөреп эшләүчеләргә башкаладан буш урыннар тәкъдим ителә.

Йолдыз Хисамиева билгеләп үткәнчә, республикада 3–7 яшьлек балаларны урнаштыру проблемасы асылда хәл ителгән. Хәзер 3 яшькә кадәрге сабыйларны яслегә урнаштыру бурычы тора. Хәзерге вакытта республикада бу күрсәткеч 80,3% тәшкил итә. Шул ук вакытта 40 районда сабыйларның барысы да яслегә йөри. Белгеч әйтүенчә, Питрәч, Лаеш, Биектау районы һәм Чаллы шәһәрендә бу мәсьәлә авыррак хәл ителә.

Быел Биектауда 140 урынлы яңа балалар бакчасы төзелгән. Узган елда республикада ясле яшендәге сабыйлар өчен 2000гә якын урын булдырылган. Быел Татарстанда барлыгы 5 балалар бакчасы төзелә.

Яңалык

Октябрь ае үзгәрешләре

Киләсе айда үз көченә керәчәк законнарның күпчелеге акчага бәйле. Барлык мөһим үзгәрешләрне тупладык.

➤1 октябрьдән керемнәр арта. Бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең һәм хәрби частьларда «погонсыз» хезмәткәрләрнең эш хакы 4 процентка үсәчәк. Бу шулай ук хәрби учреждениеләрдә һәм хәрби хезмәткә тигезләштерелгән башкарма хакимият органнарында (МВД, МЧС, ФСИН һ.б.) эшләүчеләргә дә кагыла.

➤ Банкка акча салучыларга тәгаен күпме керемгә ия булачаклары турында хәбәр ителәчәк. Килешүдә клиентның, бернигә карамастан, мәҗбүри тәртиптә күпме процентка ия булачагы күрсәтеләчәк. Шул ук вакытта бу хакта мәгълүмат зур хәрефләр белән таблицага урнаштырылачак.

➤Хәзер үзебезгә үк интернет аша финанс операцияләрен тыю яки чикләү кертү мөмкинлеге ачыла. Әйтик, акча күчерүгә лимит билгели, онлайн кредит рәсмиләштерүне тыя алачакбыз. Моның өчен банкка гариза язып, нинди чикләүләрне билгеләргә кирәклеге күрсәтеләчәк. Бу законның мошенниклыкны киметәчәге көздә тотыла. Моннан тыш банклар онлайн операциядә файдаланылучы электрон җайланманың (компьютер, смартфонның) кемнеке булуын ачыкларга тиеш: моның өчен электрон почтаны һәм телефон номерын расларга кирәк булачак.

➤Сиксән яшьтән узган кешеләрнең пенсиясе индексацияләнәчәк. Аның төп өлеше (6,5 мең сумга якын) ике тапкыр үсә. Моның өчен гариза язарга кирәкми: пенсия күләме автомат рәвештә арта.

➤Йөртүчеләргә тест режимында электрон таныклык күрсәтү рөхсәт ителәчәк. Яңа электрон сервис «Госуслуги Авто» кушымтасында сынап карала. Хәзерге вакытта юл хәрәкәте кагыйдәләренә бу җәһәттән үзгәрешләр кертелә.

➤Бөлгенлеккә төшүне туктатып тору (1 октябрьгә кадәр гамәлдә була) озайтылмаячак. Хәтерләсәгез, бу чара илдә ике тапкыр – ковидка каршы чикләүләр аркасында һәм Россиягә санкцияләр игълан ителгәннән соң кертелде. Икътисади үсеш министры Максим Решетников әйтүенчә, хәзер әлеге мәсьәлә эшмәкәрләрнең һәркайсы белән аерым тәртиптә каралачак.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Фәрит БИКЧӘНТӘЕВ, Галиәсгар Камал исемендәге академия театры баш режиссеры:

Мин, театр – бина түгел, дигән сүзләр белән тулысынча килешәм. Шуңа күрә яңа урынга әзер материал белән бармаска кирәк. Юкса без бинаны да, үзебезне дә бетерәчәкбез. Димәк, башта яңа урынга яраклы контент булдырырга, аннан соң гына тамашачыларга ишекне ачарга кирәк.

«Татар-информ»нан

РОССИЯДӘ – СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘН ФАЙДАЛАНУ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россиядә яшәүчеләрнең социаль челтәрләргә бәйлелеген белешкән.



Ярты елда – 25 миллиард сум

Ярты ел эчендә Татарстанда маркетплейслар аша сату итүче урта һәм кече эшмәкәрләр саны 37 процентка арткан.

Шушы вакыт эчендә алар 25 миллиард сум табыш алган. Чагыштыру өчен: узган ел интернет сату мәйданчыкларыннан ел дәвамында шундый табыш алынган булган. Татарстан Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрид Габделганиев сүзләренә караганда, ел азагына кадәр маркетплейслардан алынган табыш күләме 50 миллиард сумга кадәр җитәр дип көтелә.

«Татарстан интернет сәүдәнең активлыгы буенча алдынгы Идел буе төбәкләре рәтенә чыкты. Интернет сәүдә бүгенге катлаулы шартларда да үсүен дәвам итә. Белгечләр быел маркетплейслардагы заказлар саны 63 процентка артып, 2,8 миллиард товар берәмлеге тәшкил итәр дип фаразлый», – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда.

Солдатларга ярдәм

Татарстан Диния нәзарәте махсус хәрби операциядә катнашучы Татарстан солдатларына ярдәм йөзеннән акча җыю турында игълан итә. Бу хакта Диния нәзарәте матбугат хезмәте яза.

Җыелган акчага иң беренче чиратта термокием, җылы оекбашлар һәм перчаткалар, аптечкалар, армия өчен хәләл коры паеклар, тушенка сатып алырга җыеналар. Теләге булган һәркем үз өлешен кертә ала. Акча җыюны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды башкара.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

МЕЛОНИ РОССИЯГӘ ДУСМЫ, ӘЛЛӘ...

«Базар паника режимына күчте» – глобаль икътисадтан дүшәмбе көнне алынган төп хәбәр әнә шул. Бу юлы сүз биржа индексларының түбәнгә очуы турында түгел әле. Финанс спекулянтлары да үзләрен тынычсыз тота, әмма кризисның төп хәбәрчесе – нефткә бәяләр төшү. «Кара алтын» исә дүшәмбе сәүдәсен Brent сортлы нефтькә 82,71 долларга кадәр түбәнәеп төгәлләде. Американың WTI сорты 77 долларга кадәр очсызланды. Җир мае март башындагы югарылыгыннан 40 процентлап да түбәнгәрәк очты. Төп сәбәп: дөнья икътисады рецессиягә тәгәрәп керեп ята. Үзәк банкларның процент ставкасын күтәрүләре дә үз сүзен әйтә. Хәер, болар икесе үзара бәйләнгән нәрсәләр. Әлеге вазгыятьне без үткән атнада фаразлаган идек. Бик куркыныч вазгыять бу. Глобаль рецессиянең башлануы бу юлы дөньякүләм зур конфликтның башлануын якынайта. Россия өчен зур чимал табышы югалу белән дә куркыныч. Нефтьнең очсызлануы Кремльнең, «түшәм» куйсалар, «кара алтын» сатуны туктату белән янавы фонында бара. Гадәти мантыйк буенча, мондый чакта бәяләр күтәрелә иде, бу юлы төшә. Димәк, дөньякүләм җитештеру нык кими дигән сүз.

Авыр икътисади хәл Европада лидерлар алмашынуның яңа бер этабын китереп чыгарды. Италиядә чиратта тыш сайлауларда «Италия кардәшләре» («Братья Италии») дигән ультрауң партия җиңеп чыкты. Аның лидеры Джордия Мелониның Премьер-министр булуы көтелә. Ультрауңнарны без фашистлар дип кабул итеп күнеккәнбез. АКШның NBC NEWS телеканалы (ул русча да тапшырулар алып бара): «Чиктән тыш уң милләтче Италиянең беренче хатын-кыз Премьер-министры булырга мөмкин. Ул үзен берьюлы традицион консерватор дип игълан итмәкче була, әмма шул ук вакытта бу рамкага экстремистик һәм фашистик идеяләрне сыйдырырга тырыша», – диде. Әмма уңнар лидеры үзләрен фашизмда гаепләүләрне кире кага.

Сайлау алдыннан Еврокомиссия җитәкчесе Урсула фон дер Ляйен Мелони партиясенең җиңеп чыгу ихтималлыгыннан куркуын белдергән иде. Newsweek исә «Итальян премьеры итеп евроскептик Джорджия Мелониның сайлануы Россияне шатландыра, Көнбатышның хәсрәтләндерә», – диде. Мелони, чынлап та, Путинга симпатия белдергән шәхес (Европа уң экстремистлары никтер Путинны яраталар гадәттә). Әмма бу юлы эш нечкәрәк. CNN аны Муссолини белән тиңләсә дә, яңа лидер катлаулырак камырдан әвәләнгән. Мелони Брюссельның нигез ташы булган күп кенә нәрсәләргә һөҗүм итмәк, әмма Украинаны коралландыру мәсьәләсендә ул Евросоюз яклы. Киевка ярдәм дәвам итәчәк. Сәбәбе: аның көрәштәшләре еллар дәвамында Россиядән ярдәм сорадылар, әмма үтенечләре кире кагылды. Россия дипломатиясе Евросоюзның рәсми хакимиятләре карарына буйсынып оппозициягә булышмаска дигән кагыйдәне төгәл үтәде. Шуңа күрә Европа илләрендә хакимлеккә килгән уң оппозиция (мәсәлән, Швециядә дә шул хәл) Россиягә каршы, диләр белгечләр. Вәләкин әле Мелони Италия Президенты билгеләп куйгач кына (билгеләнәчәгенә шик юк) хөкүмәт кәнәфиенә утырачак. Утыргач, ни әйтер тагын.

Россиядә

БАЗАР ИКЪТИСАДЫНА МӘЙДАН ТАРАЯ

Өлешчә мобилизация игълан ителгәннән соңгы көннәр икътисадны ныклыкка сынау көннәре булды. Юк, халык паникага бирелеп кибетләргә ташланмады бу юлы. Шикәр белән тозны тынычлыкта калдырдык. Кесәләрнең бик сай булуы, бәяләрнең инде болай да тушимне ватып чыгуы үз сүзен әйткәндер, мөгаен. Әмма фонд базарында чып-чын түнтәрелеш күзәтелде. Мосбиржа индексы 20 сентябрьдән соң 2,5 триллион сумлык капитал югалтты. Үткән атна ахырында финанс базарлары тынычланып югарыга үрмәләмәк булып караганнар иде, бар тырышлыклары юкка. Дүшәмбедә базарлар янадан түнде. Саклык банкы 7 процентка очсызланды, «Газпром» – 6,4кә, «Сургутнефтегаз» – 17гә, «Роснефть» – 12гә, «Мечел» – 17гә, «Аэрофлот» 13 процентка очсызланды. «Локо-Инвест» компаниясенең инвестицияләр буенча директоры Дмитрий Полевой: «Илдә барган хәлләр базарның моңарчы булмаган югалту дәрәҗәсендәге икътисади зыян вәгъдә итә», – дип белдерде.

Безгә, гади кулланучыларга, фонд базарындагы түнтәрелештән эссе дә, суык та түгел кебек. Әмма Көнбатыш илләре яңа санкцияләр белән яный. Смартфон, радар җиһазларын һәм лазер приборларын Россиягә сатмаска дигән тавышлар ишетелә. Димәк, базар-кибетләр ассортименты тагын кимергә мөмкин. Челнок булып, кирәкле товарны чит илләрдән ташуга да өмет аз, чөнки, бердән, чикләр ябылмыйкладыр, икенчедән, валюта арзан, әмма юк. Дүшәмбе көнне бу илләрның авторы барлык Арча банкларындагы валюта сәүдәсен тикшерде. Дурт банкның берсендә генә – Саклык банкында гына доллар сата иделәр. Запаслары күпме булгандыр, бәясе кыйммәт – 78 сум. Үзәк банк курсы кәгазьдә генә шул.

Параллель импорт безгә начар сыйфатлы һәм кыйммәт товарлар гына вәгъдә итә. Ялган товарларны популяр брендлар маркасы белән сатарга тырышу очраклары бар, диләр. Иң мөһиме – импортны үзебез җитештергән киң халык кулланучы товарлары белән алыштырырга өмет кечерәя. Икътисадны хәрби рельсларга күчерми булмый. Белгечләр бу уңайдан Россиядәге дәүләт капитализмы моделе базар секторын кысрыклау, планлы-административ икътисадка капкаларны киң ачуга китерәчәк дип фаразлыйлар. Финанс аналитигы Павел Рябов 21 сентябрьдән соң икътисадның яңа чынбарлыкка күчүен әйтә һәм: «Дәүләт капитализмының квазипланлы икътисадына күчү һәм репрессив аппаратның социаль, икътисади ирекләрне һәм капитал хәрәкәтен чиклау юнәлеше барачак», – ди. Күпләп һәм ваклап сату сәүдәсе кимер, кучемсез милек сәүдәсе тукталыр, төзелеш тармагы җимерелер дип куркалар белгечләр. Әмма медицина, мәгариф, авыл хуҗалыгы тармаклары чагыштырмача тотрыклы булыр дип тә фаразлыйлар. Без вакыйгаларның бик кызу һәм тыгыз әйләнешен күрәбез соңгы көннәрдә. Юнәлеш кискен үзгәрергә дә мөмкин, әмма әлегә каттый чикләүләр эчендә тынны кысып яшәргә туры килә.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов өлешчә мобилизация кысасында чакырылган республика хәрбиләре белән очрашты. Очрашу аларның җыю пункты булып саналган «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә узды.

Татарстан Президентына ил һәм ашау-эчү ничек оештырылганын күрсәттеләр. Билгеле булганча, Казанның азык-төлек һәм социаль туклану департаменты хәрбиләрне өч тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итәчәк. Ашханәдә 4 зонада урнашкан. Рөстәм Миңнеханов ризык сыйфатына аерым игътибар бирергә кушты.

Моннан тыш җыелу үзәгендә медицина пункты, сак булеге, сәүдә зонасы да бар. Моңа өстәп Татарстан Президенты санитар-гигиена шартларын кайгыртырга кушты. Якын арада мобиль мунчалар урнаштыру күздә тотыла.

Мобилизациягә эләккән кешеләрне бирегә 1 октябрьгә кадәр җыячаклар. Аннан исә хәрби әзерлек эшләре башланачак.

Моннан тыш Рөстәм Миңнеханов хәрби частьлар урнаштыру өчен корылган палаткалы лагерьны да карады. Ул 2500 кешегә исәпләнгән, яшәү өчен палаткалар саны – 73. Юыну, ашау-эчү, ял итү өчен бүлмәләр каралган. Ашату ике сменада оештырыла. Палаткалы лагерь җылылык белән тәэмин ителгән.

Өлешчә мобилизация кысасында хәрби хезмәткә чакырылган авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләре гаиләләренә ярдәм итәргә кирәк. Бу хакта Россия Президенты Владимир Путин кыр эшләре барышына багышланган киңәшмә вакытында әйтте. «Төбәк башлыкларына, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә дә аерым мөрәҗәгать итәсе килә. Өлешчә мобилизация кысасында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре дә чакырылы. Аларның гаиләләренә ярдәм итәргә кирәк. Бу мәсьәләгә аерым игътибар бирүегезне сорыйм», – диде ул.

Аның әйтүенчә, махсус операция һәм референдумнар барган көннәрдә бар кешегә дә билгеле, гади һәм әмма төпле «Икмәк – барысына баш» гыйбарәсенең әһәмияте бетмәде. «Хәзерге шартларда дөньядагы азык-төлек базарындагы хәлләрне исәпкә алып, бәлки әле, бу иң мөһим канунлык берсенә дә әверелгәндер. Шуңа күрә мин хәзергә кадәр башкарылган эшләр өчен рәхмәт белдерәм», – диде Россия Президенты.

Уртак фикер

Донецк һәм Луганск халык республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләрендә Россия составына керү турында референдум тәмамланды. Биш көнлек тавыш бирү 23 сентябрьдә башланган иде.

Беренче дүрт көннән соң дүрт төбәктә дә референдумда катнашучылар 60 проценттан артып китте. Әйтик, ДНРда – халыкның 86,89 проценты, ЛНРда – 83,6, Запорожье өлкәсендә – 66,43, Херсон өлкәсендә 63,58 проценты әлеге төбәкләрең язмышын хәл итәчәк мәсьәләдә үз фикерен белдерергә өлгергән.

Билгеле булганча, сайлау участоклары Татарстанда да ачылды. Катнашучыларның фикере уртак: алар бу референдумга тынычлык буласына өметләнеп килгән. Казанда тавыш биргән Ольга ханым Татарстанга апрель аенда ДНРдан күчеп килгән. Киләчәктә ул туган ягына кайтырга өметләнә. «Яшермим: без Россиягә кушылуны яклап тавыш бирдек», – ди ул.

Менделеевскида тавыш биргән Нина Исакова Татарстанга Донбасстагы Краматорск каласыннан күчеп килгән. «Без Донбассның Россиягә кушылуын күптән көттек. Бүген безнең өчен бәйрәм», – ди ул. ЛНРда гомер кичергән Елена Янишинаның балалары инде 2014 елдан бирле Менделеевскида яши. «Язмыш безгә дә Россиягә кайтырга насыйп итте. Барысы да Россиянең җиңәсенә ышана», – дигән ул журналистларга.

Лаеш районында сайлау участогын «Санта» шифаханәсендә оештырдылар. Референдумга килучеләрнең күбесе фикеренчә, әлеге вакыйга Донбасс кына түгел, Россиянең дә киләчәген кайгырту өчен кирәк.

Фикер

Игорь БИКЕЕВ, Татарстан Дәүләт Советы депутаты:

– Киев хакимияте, Донбасс, Херсон, Запорожьеда яшәүче тыныч халыкка туплардан атып, аларны үз гражданнары итеп кабул итүдән баш тартты. Кешеләр нәрсә эшләргә тиеш иде? Сайлау юлы бер генә: мәдәнияте, тел буенча якын булганнарга, ягъни Россиягә мөрәҗәгать итү. Патша вакытында да, совет чорында да русларны максатчан равештә бу төбәкләргә җибәргәннәр. Русларны да, татарларны да. Бу – безнең берничә буында буленеп торган туганнарыбыз, якыннарыбыз, ватандашларыбыз. Аларны язмыш кочагына калдырырга ярамый. Без алар сайлаганны кабул итәчәкбез.

ЯЛ ҮТТЕ, ТӘЭСИРЛӘР КАЛДЫ

Нәтиҗә

Җәйге ялны көзен дә онытмыйлар. Быел республика лагерьларында 154 меңнән артык бала рәхәт чиккән. Көзге каникулда 13 меңләп укучыны мәктәп яны лагерьларында көтәләр. Бу хакта Татарстан Министрлар Кабинетында үсмерләрнең җәйге ялы нәтиҗәләренә багышланган брифингта сөйләделәр.

Җәйге ялдан соң да эти-әниләр белән элемтәләр өзелми. Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов сөйләгәнчә, «Ял» республика үзәге белгечләре алардан ялның ни дәрәҗәдә сыйфатлы үтүе турында сорашуырын дәвам итә. Каникул вакытында «кайнар линия» дә эшләгән, анда 15 меңнән артык шалтырату кабул иткәннәр. Эти-әниләрне күбрәк сменаларның эчтәлеге кызыксындырган. Гомумән алганда, 98 проценты ялдан канәгать калган. Кыскасы, балалар да шат, әниләр дә.

Барлыгы 1527 лагерь эшләсә, шуларның 192се – шәһәр яны лагерьлары. Хезәр җәйге ялга күңел ачу гына түгел, өстәмә белем бирү дип карарга өйрәндек. Эти-әниләрнең күбесе социаль-педагогик (45 процент), туристик (16), спорт (12 процент) кебек профильле сменаларга өстенлек биргән. Программалар кызык булмаса, балалар ямансулап, бик тиз өйләренә кайтып китәчәк. Бу мәсьәләгә дә зур игътибар бирелгән. Җәйләүләрдә быел беренче тапкыр дәүләт флагларын күтәрү тантаналары үткән. Цифрлаштыру елы уңаеннан 29 лагерьда «Санлы дәресләр» узган. 154 мең юлламаның 31 меңнән артыгы республика бюджеты хисабына бирелгән. Авыру балалар да читтә калмаган. Аларның 500е башка яшьтәшләре белән күңел ачкан. Кемгәдер диңгез ярларын да күрү бәхете тәтегән. «Черноморец» республика үзәге директоры Евгений Ветров әйтүенчә, Кара диңгез буенда 5 меңнән артык бала ял иткән.

– Мәктәп яны лагерьларында барысы 68 меңнән артык бала һәм үсмер ял итте. Шуларның 11 меңнән артыгы – 493 хезмәт һәм ял лагеренда. Алар арасында Луганск, Донецк республикаларыннан килгән балалар да (барлык төр лагерьда ял итүчеләр –179) бар иде. Хәзерге вакытта «Заречье» лагерендә Лисичанскидан 207 бала ял итә. Алар өчен экскурсия, иҗат һәм спорт ярышлары үтә, – дип сөйләде Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының өстәмә белем бирү булеге җитәкчесе Айгөл Кашапова.

Иминлек мәсьәләсе дә – үзәктә. Быел балалар сәламәтләндерү оешмаларында иминлекне тәэмин итү өчен республика бюджетыннан 30 млн сум бүленгән. Бу акчага хосусый сак предприятиеләре хезмәткәрләрен җәлеп иткәннәр.

– Бу – зур игътибар таләп итә торган мәсьәлә. Лагерьларны шәхси сак оешмалары хезмәткәрләре белән тәэмин итү генә түгел, урыннарда эшне оештыру сыйфатына күзәтү ясау да мөһим. Сер түгел, лагерьларга яше пенсиягә җиткәннәрне дә җибәрәләр. Бу төр оешмаларның сыйфатлы итеп саклау өчен аларның яшь чиген билгеләү кирәк. Бу юнәлештә министрлык Росгвардия белән эшне көчәйтәчәк, – диде Тимур Сөләйманов.

Сәрия МИФТАХОВА

КӨЧ – БЕРДӘМЛЕКТӘ

Ватанны авыр вакытларда саклап калуның иң әһәмиятле юлы – халыклар бердәмлеге. Татарстан халыклары ассамблеясы Советының Лаешта узган күчмә утырышында төп фикер әнә шул булды.

Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе, ассамблея Советы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин Лаешка эш сәфәре кысасында районда мәктәптә иминлек саклау эшенең ничек оештырылуы белән танышты. Ул Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов исемендәге 2 нче урта мәктәптә булды.

Укытучылар белән аралашканда Фәрит Мөхәммәтшин тәрбия һәм профилактика эшен көчәйтергә кирәклеген аерым ассызыклады.

– Килеп чыккан вазгыять, Ижауда булган фаҗига безне бик борчый, – диде ул. – Сыйныф җитәкчеләренең роле һәм абруе артырга тиеш. Укучылар белән эшләргә, тискәре күренешләрне булдырмый калу өчен тырышырга кирәк. Безнең буруч – киләчәктә мондый фаҗигаләрне булдырмау. Әлбәттә, әти-әниләр дә җаваплы, әмма мәктәп тә тәрбия эшен көчәйтергә тиеш.

Дәүләт Советы Рәисе шулай ук мәктәптә туган телләрне ничек өйрәнүләре, төрле халыкларның гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү эшенең оештырылуы белән кызыксынды. Укучылар парламент башлыгын үз туган телләрендә сәламләп каршы алдылар. Мәктәптә гаиләләрнең нәсел шәҗәрәсен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. «Гаилә традицияләрен саклау, аларны буыннан-буынга тапшыру, шул рәвешле яшьләрне тәрбияләү мөһим», – диде Мөхәммәтшин.

Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов сүзләренчә, Лаешта күпмилләтле халык үз гореф-гадәтләрен саклап, тыныч һәм бербересен хөрмәт итеп яши. Районда 55 мең ярым кеше яши. Аларның 55 проценты – руслар, 42 проценты – татарлар, 3 проценты – керәшеннәр, азәрбайҗаннар һәм башкалар.

Фәрит Мөхәммәтшин илдәге катлаулы вазгыятьтә бердәмлекнең кадере һәм әһәмияте тагын да артуын искәртте.

– Бик җаваплы чорда яшибез. Моны һәркем үзендә сизә. Бу авырлыкларны җиңеп чыгар өчен без бердәм булырга тиеш. Бер-беребезгә хөрмәт белән карау – бүген төп кыйммәтләр, – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин Украинадагы махсус операциягә мәҗбүри чара дип атады. Бүген исә аңлату эше белән шөгыльләнү, кабул ителгән карарларның дөреслегенә инандыру, Донецк һәм Луганск халык республикаларында яшәүче кешеләргә ярдәм итү бик мөһим. «Халыклар ассамблеясы фундаменталь кыйммәтләрне, милләтара һәм конфессиара тынычлыкны һәм татулыкны яклый. Бүген милли-мәдәни берләшмә вәкилләре, моңарчы булмаганча, кешеләр арасында, ватандашлары арасында булырга тиеш», – диде ул.

Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Фәнни педагогик эшчәнлегендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты (ИЭУП)» югары белем бирү шәхси мәгариф учреждениесе проректоры **Антонова** Ирина Илгиз кызы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

Кысадан чыгу

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Мөнәсәбәт нинди?

Белем генә түгел, тәрбия дә кирәк. Татарстанның Иҗтимагый палата рәисе урынбасары Рафил Ногманов шул фикердә. «Элек пионер, комсомол, октябрят ише күп кенә оешмалар бар иде. Баланың башына да шулар аша акыллы уйлар, яхшы хисләр керә иде. Белем бирү генә җитми. Тәрбия, акыл ягын аз кайгыртабыз. Интернет йогынтысы бар. Ата-аналар да балалар белән шөгыльләнми. Югыйсә кызыксынып торырга кирәк бит, аралашу даирәсен дә белергә», – ди ул.

Өч бала анасы, «Тәртип» радиосының PR-белгече Айсылу Лерон әйтүенчә, яшьлеккә кирелек, башбирмәслек хас. Сәерлекләр дә теләсә кайсы чорда очраган.

– Без үсканда да әллә нинди күренешләр булды. Эмо, гот ише агымнар, әйтик. Үземне бу шаукым урап узды, миндә бүтәннәрдән аерылып тору теләге булмагандыр. Әмма яшьтәшләрем арасында андыйлар булды. Үзенә күрә табигыйдер бар инде бу. Чөнки үсмер чакта бунтарьлык, киресен эшләргә тырышу, мөстәкыйльлеккә омтылу бар, бу – җитлегүнең бер этабы. Ләкин бу агымнар куркыныч якка да әверелергә мөмкин, – ди ул. – Хәзерге яшь буынның кумирлары – тиктокерлар. Әле менә яңалык укыдым: Белоруссиядә берсе үзенең сәхифәсендә фәлән-фәлән сәүдә үзәгендә чыгыш ясыйм, килегез дигән һәм берничә сәгатьтә шул үзәкка меңнәрләгән кеше җыелган. Яшьләр өчен кемнәр үрнәк булуы аңлашыладыр. Безгә исә аңларга кирәк: ни өчен аларны үрнәк саныйлар? Нигә җәмгыятькә, илгә хезмәт итүчеләр, файда китерүче акыллы шәхесләр алар өчен кумир түгел? Җавабы да бар инде, озак уйлап торасы юк: тиктокерлар – популяр, кыска гына видеолары белән күп итеп акча эшли. Ә яшьләрнең матур киенәсе, тәмле ашыйсы, яхшы тормышта яшисе килә.

P.S. Язма теге яисә бу юнәлешне пропагандалау өчен түгел, киресенчә, бу агымнарның тискәре йогынтысын күрсәтү максатыннан әзерләнде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТӨЛКЕ КЕШЕДӘН КУРЫКМЫЙ

КОТЫРГАН ТӨЛКЕНЕҢ БИЛГЕЛӘРЕ:

- үз-үзен тотышында үзгәрешләр;
- кешедән курыкмау;
- теле асылынып тору;
- йөрү рәвеше үзгәрү;
- күп итеп сеңгәе агу.

Яшәеш

Татарстанның авыл-шәһәрләрендә урман хайваннарын очрату кыен түгел. Авылда урам уртасында куяннар йөреп тора, төлкеләр дә кунакка килергә күп сорамый. Кыскасы, җәнлекләр кешедән курыкмый башлады.

Моннан берничә көн элек үзем дә Казан үзәгендә төлке күрергә туры килде. Шул вакыйга икенчесен искә төшерде. Моннан 26 ел элек күрше авылга кунакка барган идек. Баруын машина белән бардык, кайтуын җәяүләп кайтырга булдык. Үз авылыбызга җитәрәк, урманнан зур төлке килеп чыкмасынмы? Нишләргә? Бар көчемне җыеп кычкырып җибәрүем булды, төлкедән җилләр исте. Ә хәзергеләрен курыкытам димә. Ни өчен төлкеләр еш кунакка килә башлады? Без бу сорауны КФУ профессоры Илгизәр Рәхимовка бирдек. Аның фикеренчә, гаеп төлкедә түгел, аны төшереп социаль челтәрләргә куйган кешедә.

– Төлкеләр элек-электән авылларга йөрде. Шәһәрләргә дә иркенләп керә башладылар. Әмма алар күп түгел. Сезнең берәрегезнең атна буе урамда көтүе белән йөргән төлке күргәнегез бармы? Юк. Алар төрле җирдә йөриләр, – ди Илгизәр Рәхимов. – Үзенең дә Казан үзәгендә соры куян белән очрашканым булды. Әгәр аларны куркытмасалар, тыныч кына яшиләр. Кешегә тими икән, алардан куркырга кирәкми. Соңгы елларда халык бер төлке күрә дә шуны социаль челтәрләр аша тарата. Бер видео күп кешегә эләгеп, куркы тудыра. Шуңа күрә төлке күрүне зур вакыйга итмәскә иде.

Кукмара районында да төлкеләр еш кунак. Төркәш авылында гомер итүче Дания Йосыпова, авыл урамнарында йөрмәсәләр дә, бакчаларда, басуларда күренәләр, ди.

– Башка авылга йөреп эшлибез. Юл буйларында төлкеләр күренгәли. Әмма алар кешегә тими. Үзебез дә иялаштек инде, – ди ул. – Авыл эчендә бер ташландык бакча бар. Шунда шулкадәр күп куяннары йөри. Җәйдән бирле яшиләр инде. Аларны да кызганам. Азык эзләп килүләрдер, мөгаен.

Татарстанның Биоресурслар буенча дәүләт комитетының Хайваннарны мониторинглау булеге җитәкчесе Илфат Вәлиев тә, кыргый җәнлекләр авылларга һәм шәһәргә азык эзләп килә, ди.

– Җәнлекләр дә ансат кына ризык табуга иялашеп килә. Үзенә кыяндыр тотып алганчы, эзләп тапканчы, ачык савытлардагы калдыкларга кызыгалар. Күпчелек төлкеләр урынга иялашә дә гел шунда азык эзләп килә, – ди ул. – Татарстан урманнарында төлкеләр арткан дип әйтеп булмый. Аларның баш саны, һәр елдагыча, 7 мең тирәсендә тора. Кыш көннәрендә дә төлкеләрнең авыл-шәһәрләргә килүе күзәтелергә мөмкин. Алар ач булса, йә котырган булса, кеше арасына килә.

Белгеч фикеренчә, котырган төлкене кешедән курыкмый. Әгәр сез төлке белән очрашсагыз исә, янына бармагыз. Киткәннен торыгыз яки акрын гына башка якка таба атлап, тиз генә бу урынга ветеринар чакыртыгыз. Төлке кешегә ташланмый. Фәкать аны котыртмаска кирәк. Әгәр инде тешләп өлгергән икән, яраны антисептик белән эшкәртергә һәм табибка барырга киңәш ителә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

vk.com

КИЧ

Алсу кояш карап тора
Яфраклар арасыннан.
Тып итеп өзелер кебек
Өлгергән алма сыман.

Койма башына малайлар
Утырганнар тезелеп.
Күзәтәләр шул алманы:
Кайда төшәр өзелеп?

Офыктагы карурманга
Өзелеп төшәр менә.
Кара урман керпе кебек
Эләчәк энәсенә...

Аргы якка сикерәләр –
Үкенечкә калмасын! –
Алып чыгыйк бер, булмаса,
Салих бабай алмасын!..

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

Олы йөрәкле кеше

Сүзем – Әлдермеш авылы егете, Биектау районының Галимҗан Баруди исемен йөртүче 4 нче гомуми белем мәктәбендә директор булып эшләүче Рамил Гаязов турында. Без, әти-әниләр, аның хакында бары тик яхшы фикердә генә. Үз эшен яратып башкаручы кеше турында башкача әйтеп тә булмыйдыр инде ул.

Рамил Гаязов гомерен балалар укытуга багышлаган. Берничә ел физкультура дәресләрен укыткач, аны башта район башкарма комитетының яшьләр һәм спорт бүлеге, аннары мәгариф бүлеге җитәкчесе итеп билгелиләр. Соңрак яңа мәктәпкә директор итеп чакыралар.

Олы йөрәкле кеше ул. Белмәгән эше юк. Берәүнең дә үтенечен кире какмый. Мәктәпне тәртиптә тота. Безнең уку йортында бик күпләр белем алырга кызыга. Башкаланыкыннан бер җире дә ким түгел. Бер түбә астында музыка, сәнгать мәктәпләре урнашкан. Дәресләрдән соң балаларга җаны теләгән эш белән шөгыльләнү мөмкинлеге дә бар. Боларның барысы да Рамил Гаязов тырышлыгы белән эшләнде. Заманында Биектау районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин аңа мәктәп төзетүне дә, җитәкләүне дә тикмәгә генә ышанып тапшырмаган икән!

Коллектив гел эзләнүдә. 2020 елда мәктәп инженерлар лицее проектына керде. 9 нчы сыйныфка кадәр белем төп программа буенча бирелә. Аннары балалар үзләренә ошаган юнәлешне сайлыйлар. Бездә хәтта футбол сыйныфына кадәр бар. Анда малайлар гына укый.

Рамил Гаязов гаиләсендә дә үрнәк. Хатыны белән бер дигән балалар үстерделәр. Алардан игелек күреп яшиләр. Без җитәкчебезгә исәнлек-саулык телибез. Яңа уку елы көтелмәгән уңышлар, яхшы хәбәрләр генә алып килсен.

Лилия ГЫЙЛАҖЕВА

Туган тел – уңыш ачкычы

Хәзерге заман мөмкинлекләре ерак чит ил татарларына татар телендә алып барыла торган теле-радио каналларына да юл ача. Һәм күп урыннарда моннан ныклап файдаланалар да. «Татарстан – Яңа Гасыр Планета» телеканалы хәзер күп җирләргә үтеп керде. Чит илләрдә, мәсәлән, АКШ башкаласы Вашингтонда «Татар радиосы», «Тәртип»не, «Азатлык»ны тыңлыйлар. Боларына мин үзем шаһит. Вашингтонда гомер кичерүче мәшһүр милләттәшебез Сәгыйт абый Сәлахның йортында үземнең шушы каналлардан татар тапшыруларын тыңлап хозурланганым бар.

Форсаттан файдаланып, шушы шәхес язмышына тукталып китәсем килә. Сәгыйт абый Кореяда Сеул шәһәрендә туып-үскән. Шушы шәһәрдә үткән гасырның 50 нче елларында нибары 26 татар гаиләсе яшәгән. Араларындагы бер мәрхәмәтле татар бае шушы шәһәрдә татар мәктәбе һәм мәчет булдырган. Мәктәп өчен татар китаплары Япониядә бастырыла торган булган. Алар Сеулга шуннан китертелгән. Сәгыйт абый шушы мәктәптә белем алган. Тик үткән гасырның 50 нче еллары башында Кореяда сугыш башлану сәбәпле, соңгы ике классны тәмамлап өлгермәгән. Язмыш аны Америкага китергән. Ул монда бер ел эчендә урта белем алган. Дүрт ел эчендә ике югары белем иясенә әверелгән. Фән докторы булып, АКШ хөкүмәтенең атом-төш проблемалары буенча киңәшчесе дәрәҗәсенә ирешкән.

Шушы уңышларның ачкычы – туган татар телем, ди Сәгыйт абый. Ул моның өстенә камил рәвештә инглиз, япон, кытай һәм корея телләрен белә. Туган тел аны татар итеп саклаган, зур фән юлына чыгарган. Милли хисләре кайнап тору сәбәпле, ул үзенә лаеклы пар тапкан. Равия ханым белән ике татар баласы үстереп, аларны зур тормыш юлына чыгара алганнар. Шул ук АКШта, Финляндиядә, Кытайда һәм башка илләрдә моңа охшаш мисаллар күп. Тел һәм милли моң аларны татар итеп саклый.

Индүс ТАҺИРОВ

ИСКЕРДӘ ИСКӘН ҖИЛЛӘР

Тубыл шәһәреннән 19 чакрым ераклыкта, Иртыш елгасы буенда, XV–XVI гасырларда Себер халыкларының хәрби ныгытмасы булуы мәгълүм. Ул Искер исеме белән йөртелә. Шәһәр XV гасыр ахырында Себер ханлыгының башкаласына әверелә. 1582 елда исә аны Ермак гаскәре басып ала, шәһәр талана һәм тулысынча диярлек җимерелә. Күчем хан гаскәре белән бәрелешләрдә Ермак Иртыш елгасының Вагай һәм Күбәк авыллары арасындагы бер урында батып һәлак була. Хәзер Күбәкнең бер урамы Күчем хан исемен йөртә.

Гасырлар уза, шәһәр булган урынның күп өлеше су астында кала. Шулай итеп, Искер дә, аның урыны да юкка чыга. Әмма буыннар аша килгән хәтер җуелмый. Соңгы елларда Төмән өлкәсенең татар оешмалары Искер шәһәре урнашкан тирәлекне тарихи һәйкәл рәвешендә саклап калу турында тәкъдим белән Россия хөкүмәтенә мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә Искер шәһәре тирәләре һәм Сүзге тау федераль әһәмиятле тарихи-мәдәни һәйкәлләр исәбенә керә һәм дәүләт тарафыннан саклана. Хәзер инде Себер ханлыгы башкаласы Искер – яңарып килүче шәһәр. Анда биналар да торгызыла башлаган.

Соңгы елларда Искер шәһәре булган җирләрдә «Искер җыены» фестивале үтә. Җыен кыска гына вакыт эчендә халыкара дәрәҗәгә күтәрелә. Анда катнашу, үткәннәребезгә бәйле бәйрәмне күрү өчен, быел да татар конгрессы белән берлектә галимнәр, этнографлар, төбәкне өйрәнүчеләр, гомумән, себер татарлары үткәннәре белән кызыксынучылар Тубыл каласына юл алды. Быел «Искер җыены» халыкара фестивале 13 нче тапкыр узды. Беренче көнне себер татарларының тарихи-мәдәни һәйкәлләрен, Себер ханлыгы башкаласы Искер истәлекләрен торгызу темасына багышланган 14 нче халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Гыйльми җыенда Россиянең төрле шәһәрләреннән вәкилләр бар иде. Һәр доклад себер татарлары, гомумән, төрки халыкларның тарихын, мәдәниятен, телен саклауга кагылышлы мәсьәләләргә барып тоташты яки мәдәни бәгланышларга бәйле сәхифәләрне ачып җибәрде. Фәнни җыенда шулай ук үткәннәргә бәйле истәлекле урыннарны мәңгеләштерү турында да сөйләшү булды.

«Искер җыены»н ачу тантанасында да катнаштык. Бу җирләрнең тарихы белән таныштырганнан соң, мәйданга ат менгән Күчем хан белән аның яраткан хатыны Сүзге килеп керде һәм, аттан төшеп, сәхнәгә узды. XI–XII гасырларда Себер ханлыгындагы тарихи вакыйгаларны эченә алган сәхнәләштерелгән күренешләр дә үткәннәрдәге сәхифәләрне яңартты. Күчем хан һәм Сүзге ханбикәнең тирмәсе беркемне дә битараф калдырмады. Борынгы милли бизәкләрне кертеп, кулдан сугылган затлы келәмнәр, хайван тиреләре, мендәрләр белән бизәлгән тирмә себер татарларының әүвәлге тормышын да күзалларга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, фестивальгә килүчеләр җирле осталар иҗат иткән гамәли сәнгать әйберләрен, Себер тарихына кагылышлы ядкәрләр – музей экспонатлары, борынгы савыт-сабалар, сандык, тастымаллар, эш коралларын да кызыксынып карады. Бәйрәмдә шулай ук тирә-күрше авылларда яшәүчеләр әзерләп килгән милли ризыклардан корылган табындагы тәм-том белән сыйланырга мөмкин иде. Махсус әзерләнгән мәйданчыкта милли бәйге-уеннарда катнашып, үз көчләрен сынап караучылар да күп булды.

Җыр-моң сөючеләрнең иң көтеп алганы «Искер җыены» фестиваленең гала-концерты булгандыр. Ул Тубылның «Синтез» мәдәният сараенда узды. Залда алма төшәр урын да юк иде. Бу көнне бирелдә «Вокал», «Инструменталь осталык», «Хореография», «Сәнгатьле сөйләм», «Декоратив-гамәли сәнгать» кебек номинацияләрдә җиңүче булып бәяләнгән фольклор һәм музыкаль ансамбльләр, җырчылар, биючеләр чыгыш ясады. Концертта Татарстан артистлары чыгышлары аеруча көчле алкышларга күмелде.

Лилия ӘСКӘРОВА

БӘЙРӘМ НИ ӨЧЕН КИРӘК?

Әлмәт шәһәренең 26 нчы «Чыршыкай» балалар бакчасында сабыйларга төрле халыклар фольклорын өйрәтәләр. Бигрәк тә рус халык иҗаты, халык бәйрәмнәре аша таныштыруга зур игътибар бирелә.

Ни өчен нәкъ менә бәйрәмнәргә мөрәҗәгать иттек дисезме? Мондый бәйрәмнәр балаларга үз халкының бер кисәкчеге итеп тоярга, аның гореф-гадәтләрен белеп, иҗади сәләтләрен үстерергә ярдәм итә. Алар табигатькә, туган якка, ата-бабаларына, халык тарихына сакчыл карарга өйрәнәләр. Ел саен без балалар бакчасында Көз бәйрәме, Песнәк көне, Яңа ел, Коймак бәйрәме, Пасха, Тургай көне кебек төрле чаралар үткәрәбез. Балалар бик теләп җырлар җырлыйлар, бииләр, халык уеннары уйныйлар, бер үк вакытта көч-дәрт, талант һәм осталык күрсәтәләр.

Зөлфия КАДЫЙРОВА

БОРЫНГЫ КОЕ

Кое бәйрәме. Зәй елгасы буенда урнашкан Каенлы авылында үткән чара шулай дип аталды. Чишмә, коеларны халык борын-борыннан бик саклаган. Кеше соңгы сулышын алган чакта да алтын-көмешләрен сорамый, аңа җан әрнүен басарга бер йотым булса да су кирәк. Ә чишмә, коеның салкын суы булса, бу инде иң сихәтле даруларыңны да бер читкә куя. Коелар су чыганагы гына түгел, уттан саклап торучы ышанычлы терәк тә булган. Ут-күз чыкса, суга кая барасың? Иң беренче коега. Кызганыч, алар да юкка чыгып бетеп баралар авылларда.

Элегрәк, әле җир астыннан торбалар сузылып, су колонкалары куелганчы, Каенлыда 20ләп кое булган, алар планлаштырылып казылган һәм һәрберсенең исеме булган. Мәсәлән, Әбделгази коесы, Хәерлебанат коесы, Әһли коесы, Вафа коесы, Мөшфика коесы, Маһирауза коесы, Кәкәм коесы, Шәми коесы. Хәсәнша коесының суы каты булса да, мал-туар эчертергә бик әйбәт булган. Тәмле сулы Фәсхи коесын: «Чәйгә суны шуннан алып кайта идек», – дип искә ала өлкәннәр. Аны Исмәгыйль коесы дип тә йөрткәннәр. Озак еллар Сәлах мулла, Мәрьям коесыннан да файдаланды авыл халкы. Суы бик тәмле булган. Сәлах мулла күрмәсен дип, шыпырт кына керә торган булган кызлар суга. Тик соңгы елларда суы тәмсезләнгән. Имеш, бозын чапканда балта төшеп киткән, ул бакыр булган, реакция биреп, судан бакыр тәме килә, дигәннәр. Шулай итеп кое күмелгән. Фәррах коесы иң соңыннан юкка чыгарыла. Ул авыл кырыендарак, колхоз фермасына якын. Ферма маллары да шуннан эчертелгән. Суны ат белән җәен – арбага, кышын чанага кисмәкләр утыртып ташыганнар. Кышын кое яны бозланып ката торган булган. Колхоз фермасында эшләүчеләргә бик авырга килгән инде ул елларда. Маллар өчен күпме су ташырга кирәк бит! Атлар абзарының үзенең коелары булган. Башкача ул кадәр терлекне ничек су белән тәэмин итәсең?

Хәзер бу коелар юк инде, күптән күмелгәннәр. Цивилизация уңайлыклары, краннардан агып торган сулар коеларны кысрыклады, тик Каенлыда суы эчәргә яраклы бердәнбер Сәүбән коесы әле дә саклана. Туксанынчы елларда ук аның турында «100 яшьлек кое» дип әйтәләр иде. Авылның иң өлкәннәре дә шушы Татарстан урамында яши. Бәлки, яшьлекләрендә шушы кое суын эчкәнгә, алар озын гомерледер? Коега исеме бирелгән Сәүбән абыйның җәмәгате Маһиҗамал әби, 100 яшен тутырып, ахирәткә күчте. Инде аларның кызы Асия апага да апрель аенда 95 яшь тулды. Вәлиева Саимә апага – 93 яшь, Сөләйманова Саимә апага 15 июльдә 91 яшь тулды. Авылның иң өлкән ир-аты туксан яшьлек Ибраһимов Наил абый да шушы урамда яши. Ковид алып китмәгән булса, 100гә якынлашып килүче Кәримә апа да бу бәйрәмнең яме булыр иде. Күпләрне Сәүбән коесы туендырган, коендырган. Бала тугач, коедан су ташып коендырганнар, кеше вафат булгач, коедан су ташып юганнар.

Сәүбән коесының тарихы зур... Башта Шәрәфетдин коесы дип тә йөрткәннәр. Авылга нигез салынгач, бу тирәдә иңкүлек, ат коена торган күл булган. Калкурак урынында гомер-гомергә кое булган, диләр. Аны карап, гел яңартып торганнар. Суы тәмле булганга, чәй суын шуннан алган авылдашлар. Кирәк булганда аннан әле дә су алырга була. Сәүбән абыйлар нигезенә якын булгач, коены гел кайгыртып торгач, аның исемен биргәннәр.

Маһиҗамал әби бу нигезгә – Герман сугышыннан бер аяксыз кайткан Сәүбән исемле егеткә 1921 елгы ачлык елында кияүгә чыга. Бу гаиләдә корылыкны җиңәргә, кое суын эшкә җигәргә булалар. (Бәрәңгең булса, ач калмыйсың.) Һәм шулай эшлиләр дә. Күршеләре, буш эш дип, алардан көлә. Маһиҗамал апалар су сибү белән бергә бәрәңге бакчасын да саклыйлар. Тырышлыклары ачлык елын исәнимин җиңәргә ярдәм итә. Көзгә бөтен авылда бәрәңге булмаганда, алар су сибеп, саклап үстереп, бәрәңгедән мул уңыш алалар. Алабута онын да күпләп әзерләгән булалар.

1990 елда «Туган як» фотохәбәрчесе Николай Утеганов Маһиҗамал әбине кое янында фотога төшерә. Аның тарихы болайрак. Яруллин Илфат кем беләндер урам буйлап килә, нәрсәдер эшләп йөрүләре. Кәефенең шәп чаклары. Маһи әби капка төбендә утыра. «Йөрисез инде шунда, шушы коены да рәтләп бирмисез, бурасы черегән», – ди. Илфат: «Хәзер алып киләм кое төзекләндерүчене», – дип китә дә, авыл, совхоз тормышын яктырту ниятеннән килгән Утегановны алып килә. Әби аңа да: «Коебызның суы тәмле, тик эчәргә яраксыз, бурасы черегән», – дигән була. Фото һәм мәкалә газетада басылгач, авыл советы, совхоз җитәкчелеге коены төзекләндереп куя.

Коега бәйле төрле кызык һәм кызганыч хәлләр дә булып тора. Менә урам тулып көтү кайта. Саимә апаның кәҗә бәрәне коега төшеп китә. Апа борчылып йөгереп килә. Шәрәфиев Рөстәмнең малай чагы. Бәйләп төшереп, Рөстәм кәҗә бәтиен – коедан, коены кәҗәдән коткарды, дип сөйләгәннәре бар.

Коелар, чишмәләр кешегә авыр чакта, хәле киткәндә ярдәм итә. Ә без аларга авыр вакытта ярдәм итә алабызмы соң? Коеларны чистарту, төзекләндерү без – кешеләрнең изге бурычы. Авылда аларны һәрвакыт карап, чистартып торганнар. Аның шул эшне башкарып остарган үз кешеләре булган. Мәсәлән, Үчкә авылыннан бер хатын килеп чистарта торган булган. Урамдашыбыз Юнысов Хафиз абыйның Сәүбән коесын чистартканын әле дә хәтерлиләр. Тагын Кече Җирекледән Василий атлы кеше чистарта торган булган. Маһиҗамал әби аның, эшен бетереп, коедан чыгуына мунча ягып торган. Узган ел бу урам ир-атлары Шәрәфиев Рөстәм, Ильясов Ринат, Гомәров Госман (кемнедер әйтми калдырсам, гафу итәрсез) коены тагын чистартып, яңартып куйдылар.

Кое бәйрәмендә әнә шулар турында сүз барды. Яңгырлар яумаган, суның бер тамчысы да әҗәл даруына торган җәйге челләдә коены хөрмәтләү, аңа килеп догалар укып «эндәшү»дән дә саваплы гамәл юктыр ул. Авылның Татарстан урамында үткән бу бәйрәм дә Коръән сүрәләре укып башланды. Шушы урамда яшәүче җырга-моңга бай, нәфис сүзгә, биюгә оста авылдашлар, аларның оныклары, киленнәре рәхәтләнеп ял иттерделәр. Сыйлы табын янында, кое суыннан куйган шифалы чәйләр эчкәндә, һәркем илгә-көнгә тынычлык, авыл өстенә, ил өстенә шифалы яңгырлар теләде.

Флера ГАРИПОВА.
Түбән Кама районы Каенлы авылы

Белдерү

Администрация Арского муниципального района Республики Татарстан извещает участников общей долевой собственности на земельный участок из земель сельскохозяйственного назначения, кадастровый номер 16:09:000000:380 (16:09:070905:18), расположенный по адресу: Республика Татарстан, Арский муниципальный район, КП «Турнали», о проведении общего собрания.

Дата проведения собрания: 30 ноября 2022 года.

Адрес места проведения собрания: Республика Татарстан, Арский район, посёлок Урняк, ул. Лесная, д. 44А.

Время начала регистрации: 11.00 ч. местного времени.

Время открытия собрания: 12.00 ч. местного времени.

Повестка общего собрания:

1. Выборы председателя и секретаря общего собрания; определение правомочности общего собрания; утверждение списка участников общей долевой собственности на земельный участок.

2. Избрание лица, уполномоченного от имени участников долевой собственности действовать без доверенности: совершать все необходимые действия, связанные с отводом, межеванием, исправлением реестровой ошибки, уточнением границ и постановкой на государственный кадастровый учет земельного участка (частей земельного участка) с кадастровым номером 16:09:000000:380 (16:09:070905:18), в том числе представлять интересы в Управлении Федеральной службы государственной регистрации, кадастра и картографии по РТ и его территориальных отделах, во всех государственных и муниципальных учреждениях Республики Татарстан, в связи с чем совершать все необходимые действия, связанные с постановкой на государственный кадастровый учет и учет изменений, с уточнением земельного участка (частей земельного участка), в отношении земельного участка, находящегося в долевой собственности, и образуемых из него земельных участков, снятии с кадастрового учета земельных участков и их частей, получении сведений государственного кадастра недвижимости, а также совершать иные действия с согласованием и уточнением границ всех смежных земельных участков, с правом подписи в обращениях, заявлениях, актах согласования, межевых планах, извещениях и протоколах, с правом предоставления и отзыва необходимых документов, а также совершать иные действия.

3. Адрес места ознакомления с документами по вопросам, вынесенным на обсуждении общего собрания: РТ, г. Казань, ул. Ташаяк, д. 2а, офис 24. Срок ознакомления: в течение 30 дней с момента публикации извещения о проведений собрания участников долевой собственности.

К участию в голосовании по вопросам повестки собрания допускаются только лица, предоставившие документы, удостоверяющие право на земельную долю, а также документы, удостоверяющие полномочия доверенного лица.

Үз йортыңда

Йорт дигәндә мин өйне генә түгел, ә тоташ биләмәне – ихатасын да, абзар-курасын да, бакчасын да, башкасын да күз уңында тотам әле. Авылда безнең шундыйрак нәрсә бар. Өе кечкенә инде аның, калганнары зур. Менә шунда тәртип булдырырга тырышып йөрим. Әлегә үзем генә. Шуңа күрә бөтен нәрсә дә үз өстемдә.

Эш бетәрлек түгел. Авылда эш мәңге бетми торган. Ләкин әлегә вак-төяге өелгән. Хатын-кыз аларның барысын да ничек ерып чыгадыр, аңлап та, аңлатып та булырлык түгел. Гади генә савыт-сабаны алсаң да... Пычратасың да юасың, пычратасың да юасың. Көненә әллә ничә тапкыр. Бер генә кат юмый калсаң да, тәртип югала. Өелә башлый теге. Бөтен дөньяның ямен җибәреп тора. Идәне дә шулай. Әле менә бәрәңге салырга дип, өй базын чистартып чыктым. Идән пычранды инде. Юарга туры килде. Юмасаң, аякка ияртә бит инде ул, бөтен өйгә тарала. Аннан соң һәртөрле бөҗәкләрне куркытырга дип, көл төшереп сиптем. Ниргә буйларына, сайгак асларына, бер җире дә калмады. Баз томанга күмелде, көл борхып тора. Базда ич инде, монда сине беркем дә күрми, сазда аунаган дуңгыз шикелле рәхәтләнеп кыланырга мөмкин. Шуңа мин дә көл кермәгән бер тишек-тошыкны да калдырмаска тырыштым. «Алла теләсә, иң чиста баз безнеке булачак», – дип сөенеп өскә күтәрелсәм, бөтен идән көл белән тулган. Баз авызыннан өскә күтәрелә бит инде ул. Осталыгым булмагач, мин шуны исәпкә ала белмәгәнмен. Идәнне тагын юып чыгарга туры килде. Идәне дә шулай икән аның – пычратасың да юасың, пычратасың да юасың. Кере дә шулай. Баздан идәнгә хәтле күтәрелгән көл киемеңне чиста итеп калдырамыни инде. Анысын да юарга кирәк. Мин инде ихатадагы эшләрне караштырырмын дип уйлаган идем, өйдәге шул вак-төяк белән ярты гомер үтте.

Менә болар тормышны алга җибәрә торган эшләр түгел бит инде. Ашарга пешердең, ашадың, савыт-сабаңны юып куйдың – бернәрсә дә үзгәрми. Савыт-саба юу иң авыр эшләрнең берсе инде минем өчен. Барысын да юып бетерәсең, кулыңны чайкап сөртенәсең һәм шунда берәр тәлинкәнең юылмый калганы күренә. Анысын юсаң, тагын нәрсәдер онытылып калган була. Мәгънәсез эш инде, кыскасы. Тик ансыз да булмый. Ашарга кирәк. Юарга да кирәк. Югыйсә тәртип югала. Бу эш сине алга алып бармый, тик эшләми калсаң – артка сөйри.

Балта-пычак үткерләү дә шулай инде. Эшләсәң, эшең күренми, ә эшләми калсаң – күренә.

Ихатадагы эш бүтән төрле. Нәрсәнедер сүтәсең – күренә. Нәрсәдер төзисең – күренә. Хәтта бакчаңа чыгып бәрәңге генә алсаң да – күренә. Бакчаң чистарып калган, ел әйләнәсенә җитәрлек ризыгың бар. Алга китеш сизелеп тора. Әйтик, берәр сараймы шунда, нәрсәдер төзеп куйдың, ди. Яңа әйбер матур булып ишегалдын бизәп тора бит инде. Өстәвенә анда нәрсәләрдер тутырырга мөмкин, тормыш шартларың уңайлаша, дөньяң камилләшә дигән сүз.

Йорт эшләре икегә бүленә икән: күзгә күренә һәм күренми торган эшләр. Тик аларның икесе дә кирәк һәм барысын да үзең эшләргә тиешсең икән. Гаилә әгъзалары белән. Синең генә түгел, аларның да йорты бит инде. Бу очракта мин әлегә үзем генә булгач, барысын да үзем генә эшләргә тиеш булам. Үз йортында һәр кеше үзе тәртип урнаштырырга тиеш.

Башкача була да алмый бугай инде ул. Миңа беркем дә килеп эшләп бирми бит инде. Уң як күрше, мәсәлән, бөтен эшкә дә оста, белмәгән нәрсәсе юк. Тик мин аның кереп эшләп бирүенә өметләнеп утыра алмыйм. Аның үз йорты бар, үз мәшәкатьләре дә җитәрлек. Керсә, сәер дә булыр иде. Әйтик, мин кичен кайдандыр кайтып керүгә, ул өстәл башында пычак үткерләп утырса... Яки мунча ягып йөрсә... Ну, хатының табын әзерләп маташа, ә бу хуҗалык мәшәкатьләрен карый... Башка китермәле хәл түгел бит инде...

Үз йортында һәркем үзе тәртип урнаштырырга тиеш. Пычратырга, юарга, сүтәргә, төзергә, ватарга, төзәтергә... Белмәгәнен өйрәнергә, булмаганын булдырырга тиеш. Күзгә күренә торганын да, күренми торганын да үзе эшләргә. Чөнки аңа беркем дә китереп бирми. Күршесе дә, авылдашлары да, туганнары да. Үзе нәрсәдер эшләргә тырышса, әлбәттә, ярдәм итәргә мөмкиннәр. Әмма үзе кыл да кыбырдатмаган кешегә беркем дә бер нәрсәне дә килеп эшләп бирми. Хәтта кемдер килеп тәртип урнаштырса да ул үз тәртибен урнаштыра башлый. Бу сиңа ошамый, каршы киләсең, җиңсәң – барыбер үзеңә эшләргә, ә кул кушырып утырсаң, квартирант хәлендә каласың.

Моны без барыбыз да беләбез инде. Авылда да, шәһәрдә дә шул ук хәл. Барыбызның да башыннан үткән, таныш. Шуларны уйлый-уйлый үз йортымда тәртип урнаштырып йөрим. Күңелсезрәк була башлагач, радиоалгычны кушарга булдым. Юньләп тотмый инде ул монда. Ачып җибәрү белән диярлек кытырдый башлады. Бер генә сүзен аңлап кала алдым:

– Татарстан – туган йортыбыз...

Үзе юньләп эшләмәсә дә, сүзе дөрес инде радиоалгычның.

Марат КӘБИРОВ

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының икенче чакырылыш (1999–2004) депутаты

Рамил Хәсән улы ГАЛИЕВның

арабыздан вакытсыз китүе сәбәпле, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Без дә сезнең белән югалту ачысын кичерәбез.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ЭНӘДӘН БАШЛАНГАН ИГЕЛЕК

Үрнәк

Ольга Спиридонова – яраткан шөгылен кешеләргә ярдәм итү ысулына әйләндергән кеше, «Добро с иголочки», «Цветной мир кукольного театра» проектларының авторы. «Көмеш» волонтер булса да, олыгаерга, өйдә утырырга һич ашыкмый ул. Көчне игелекле эшләрдән алам, ди үзе.

«Авырлыкларны кичерергә ярдәм итте»

Волонтерлык хәрәкәтенә соңарып кына кушыла Ольга ханым. Пенсиягә кадәр мәктәптә эшли. Ә кул эшләре электән үк яраткан шөгыле икән.

– Моны минем хезмәттәшләрем дә белә иде. Шуларның берсе минем турында мөмкинлекләре чикле балаларның әниләре белән шөгыльләнүче бер ханымга сөйләгән. Акрынлап мине әниләр белән дә, сабыйлар белән дә төрле эшләнмәләр ясарга дип, хәйрия ярминкәләренә чакыра башладылар. Шундый очрашуларның берсендә «Альпари» фондының мастер-классларына чакырдылар. Әлеге фонд белән әнә шул көннән башлап, инде менә 11 ел дәвамында дуслар без, – ди Ольга Геннадьевна.

Бу вакытта аның ире авыр хәлдә була. Балаларга ярдәм итә дә өенә ашкына. 2016 елда ашкынып янына кайтыр кешесе вафат була...

– Иремнең вафатын бик авыр кичердем. Әле дә ярый янымда балаларым булды. Мине ничек тә эшсез утыртмаска тырышты алар. Яраткан шөгылем барлыгын исемә төшереп, шуның белән шөгыльләнүемне, балаларга ярдәм итүемне туктатмаска куштылар. Сүзләрен тыңлап, янә шул эшемә «чумдым», – дип искә ала ул.

«Волонтер икәнемне белми йөргәнмен...»

2017 елда Ольга ханым «көмеш» волонтерлар хәрәкәтенә кушыла.

– Аңа кадәр үземнең волонтер икәнемне аңлап та җиткермәгәнмен (*көлә*). «Көмеш» волонтерлар турында да шунда гына белдем. Ул чакта мин аларга курчак театры оештырырга тәкъдим иттем. Артистлар – үзебез, ягъни әби-бабайлар. Курчакларын үзем ясармын, дидем. Бу идеямне бик ошаттылар, һәм без мөмкинлекләре чикле балалар өчен төрледән-төрле спектакльләр куя башладык. Мин артист түгел бит, дигән әби-бабайларга: «Онытыңа әкият укыганың юкмыни?» – дип кенә әйтә идем. И, ул курчаклар белән мәш килдек без. Балалар да шундый ошатты безнең спектакльләрне. Гомумән, авыру балалар өчен мондый чаралар бик файдалы һәм бик әһәмиятле икәнен аңладык без. Үзләре белән дә, әти-әниләре белән дә аралашкач, тагын да «канатланып» эшли башладык, – дип сөйли Ольга Геннадьевна.

«Көмеш» волонтерлар булып яше 55тән узган, җәмгыятьтәге социаль, мәдәни, экологик проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән һәм, үз белем-осталыкларын кулланып, ирекле һәм түләүсез эшчәнлек алып баручы кешеләр санала.

2018 елда узган Футбол буенча дөнья чемпионатына да махсус сценарий язып, курчаклар ярдәмендә футбол тарихын сөйләгән алар.

– Ул чакта безнең курчаклар турында «Матч ТВ» махсус сюжет та төшерде әле. Шуннан соң, 2019 елда «WorldSkills» чемпионатына махсус пьеса яздык, – дип искә ала әңгәмәдәшем.

САН
Хәзерге вакытта Татарстанда 200ләп «көмеш» волонтер бар. Ә Россия буенча аларның саны – 63,5 мең.

«Яшәргә көчне игелекле эшләрдән алам»

Ләкин энтузиазм белән генә ерак китү авыррак шул. Кул эшләнмәләре өчен махсус җиһазлар, тукымалар да кирәк бит. Барысы да – чыгым. Шуңа да Ольга ханым грант алыр өчен проектлар язарга тотына. Һәм тырышлыгы юкка китми: «Доброволец – 2020», «Молоды душой – 2021» бәйгеләрендә җиңеп, грантлар ота ул. Ул акчага тегү машиналары һәм башка кирәк-яраклар алып, эшен тагын да киңрәк җәелдерә.

– Ул тегү машиналары белән кайда гына булмадык, нинди генә остаханәләр оештырмадык инде. Чакырып торалар, без йөреп торабыз. Әле менә күптән түгел Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан килгән балалар янына барып, алар белән дә очраштык. Балаларга уенчыклар ясау буенча мастер-класс уздырмакчы идем. Ләкин анда минем башка файдам тиде: мәҗбүри эвакуацияләнүчеләргә кешеләр китергән киемнәрнең кайсын кыскарттым, кайсын зурайттым шунда. Уенчыклар онытылды анда...

Кешеләргә ярдәм итә алуына чын күңеленнән сөенә Ольга ханым. Яшәргә көчне игелекле эшләрдән алам, ди.

– Белгәнемне башкаларга да өйрәтәсем килә. Мин башкача булдыра алмыйм. Әгәр минем дәресләрем кемгәдер булыша, кемнедер бәхетле итә икән, мин дә бәхетле. Янымда да шундый кешеләр бит минем. Алар да башкаларга ярдәм итәргә атлыгып тора, – ди Ольга Спиридонова.

Картаерга вакытым юк, ди ул. Яшьтәшләренә дә тик утырмаска киңәш итә.

– Булган гомереңнең кадерен белеп яшәргә кирәк! Әйе, көнне начар уйларга «батып», зарланып, «уф»ылдап та үткәрергә була. Алай да үтә ул. Ләкин шул көнеңне файдалы эшләргә багышласаң, башкага да ярдәмең тия, үзең дә бәхетле буласың, – ди ул. – Бу турыда яшьтәшләремә гел әйтергә тырышам. Кемнедер рухландырам. Шулай берзаман поездда кайтканда Чаллыдан бер әбиең белән таныштык.Ниләр белән шөгыльләнгәнемне сөйләгән идем, таң калды. Хәзер менә төрле чараларда очрашабыз, ул да – «көмеш» волонтер. Күзләре дә яна башлаган! Аны шулай рухландырып җибәргәнем өчен миңа рәхмәт әйтүчеләр дә күп булды. Шуңа да волонтерлык турында мөмкин кадәр күбрәк сөйләргә кирәк дигән фикердә мин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТИМЕРНЕҢ ҖАНЫ БАРМЫ?

Тимер генә түгел бу, һәр машина – аерым бер тарих. Кешеләр, район, тулы бер чор истәлеге. Минзәлә автотранспорт предприятиесе янындагы автомобильләр коллекциясе белән танышкач, әнә шундый нәтиҗә ясадык.

Юлыбызга очраклы гына килеп чыккан теманы шулкадәр кызыклы булыр дип уйламаган идек югыйсә. Әлеге оешма яныннан узганда, Совет заманындагы машиналар коллекциясенә игътибар итеп, шулар янына тукталырга булдык. Һәм, чыннан да, карарыбыз юкка булып чыкмады. Оешма директоры Рамил Кәримов һәр автомобиль турында кызыклы итеп сөйләде.

«Пчела», «труженник», «лягушенок», «горбатый», «копейка», «букашка»... Халык теленә әнә шулай кереп калган легендар машиналарның һәркайсы никадәрле мәгълүмат саклый.

– Әлеге коллекциядәге машиналарның барысы да диярлек ниндидер истәлекләргә бәйле. Һәркайсы минем, гаиләм, коллектив, район өчен кадерле, – дип сүзен башлады Рамил Кәримов. – Мәсәлән, менә бу ЗИЛ-157 «Захар» машинасында кайчандыр минем абыем эшләгән иде. Нәкъ менә шушы техника рулендә машина йөртергә өйрәндек без. Йөртер өчен бик авыр машина, әмма пычрак юлларны ерып йөрүдә аңа тиңнәр юк. Менә бу ЗИЛны шулай ук безнең районда табып алып кайттык. Шактый таушалган иде. Тәртипкә китереп, төзекләндереп, анысын да шушында куярга булдык. Ә менә бу ГАЗ-50 автомобилендә заманында әти мәрхүм йөргән иде. Аны да төзекләндереп, истәлек итеп саклыйбыз.

Коллекцияне исә кайчандыр 2 нче мәктәп балаларын йөрткән автобустан башлаганнар. Анысы үзе бер символик мәгънәгә ия. Автобуслар предприятиесенә бик урынлы булган.

Хәер, коллекциядә шәхсән Рамил Кәримов өчен генә түгел, шәһәр, район өчен дә кадерле һәм әһәмиятле автомобильләр шактый.

– Монысы – коллекциядәге иң «карт» машина, – дип таныштырды ул 1957 елгы ГАЗ-69 белән. – Аны безнең колхозның элеккеге җитәкчебез Рәшит Хамадиев йөрткән. Бу машина белән чыгып китеп, күпме колхозларны, фермаларны урап узган ул. Шулай ук бик көчле машина, америкалыларның «виллис» машинасына охшатып эшләнгән. ВАЗ-2101 автомобилендә («копейка») шулай ук Минзәлә районы кешесе йөргән. «Әтиемнең исемен мәңгеләштерәсем килә», – дип тапшырды ул автомобильне. Безнең заводның иң легендар, иң кәттә автомобильләренең берсе булган. Ул, беренчедән, хәрәкәт итәр өчен җиңел булса, икенчедән, салонында һәрвакыт җылы.

Аның янәшәсендәге Москвич-423 Н автомобилен исә авыл хуҗалыгы – колхоз рәисе, агроном, инженер, зоотехниклар өчен махсус чыгарган булганнар. Заманында аны нибары 1513 данә ясаганнар. Халык телендә «лягушенок» дип даны таралган машина исә биек һәм җиңел булганлыктан, күп җиргә үтеп керергә мөмкинлек биргән һәм бәясе дә кыйммәт булмаган.

Коллекциядә данлыклы «Победа» автомобиле дә бар.

– Нәкъ менә Бөек Ватан сугышында җиңүгә атап чыгарылган машина заманында чыннан да ныклы, чыдам, бик затлы автомобиль булып саналды. Анысын без Чиләбе өлкәсеннән эзләп алып кайттык. Машиналарны әнә шулай төрле җирләрдән эзлибез. Мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен махсус чыгарылган «инвалидка» машинасын Башкортстаннан алып кайттык, – ди җитәкче.

Билгеле ки, каяндыр табып, эзләп алып кайтыр өчен шактый суммада акча да чыгарып салырга туры килә. Тик җитәкче аларның бәяләрен сер итеп калдырды. Әнә, мәсәлән, халык телендә «горбатый», «малыш», «жужик» дип телгә кергән ЗАЗ-965 «Запорожец»ын Оренбург өлкәсеннән алып кайтканнар.

– Коллекциядәге тагын бер машина ИФА («букашка», «мультик») автомобиле – КамАЗ заводының легендар автомобильләренең берсе. Төп үзенчәлеге шунда: кечкенә булуына карамастан, йөк ташырга чыдам һәм аның пычрак ерып йөрү сәләте көчле. Без аны Свердловск өлкәсеннән алып кайттык. Кызганыч, двигателе генә юк.

Коллекциядә совет машиналарыннан кала чит илдә чыгарылган автомобиль дә бар. 1990 нчы ел яшьләренең хыялы булган «Мерседес» «Волчок» – әнә шундыйларның берсе.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Ул вакытлар өчен моннан да кәттәрәк автомобиль булмаган. Чыннан да, заманасы өчен бик күп мөмкинлекләргә ия машина бу. Без аны Казаннан алып кайттык, – диде Рамил Кәримов.

Берничә машинаның кайсыдыр «органы» булмаса да, араларында эшли, хәрәкәт итә торганнары да бар. Тик аларны да бары тик күргәзмә өчен генә тоталар. Нибары ике машинаны – Москвич-401, Газ-69 автомобильләрен генә Җиңү бәйрәме, сабантуйлар, ретро автомобильләр парадында файдаланалар. Шулай ук кино төшерүдә дә кулланганнар. Әлеге вакытта коллекциядә барлыгы 13 автомобиль бар. Тагын берсен күптән түгел генә башка төбәктән алып кайтканнар. Без килгәндә анысы гаражда үз чиратын көтә иде. Төзәтеп, яңартылгач, анысын да урамга чыгарачаклар.

– Бер абзый коллекциядәге 12 машина өчен 4,5 млн сум акча тәкъдим иткән иде, ләкин без аны бирмәдек, – ди Рамил Кәримов. – Чөнки монда – безнең күңелебезнең бер өлеше. Чыннан да, бу машиналарны бик тырышып эзләгәндә сатып алырга мөмкин, ләкин бәяләре кыйммәт. Ә безнең өчен акча мөһим түгел, чөнки бу бернинди матди кыйммәтләр белән дә исәпләнми. Максатыбыз – Совет заманының автомобиль сәнәгатен хәтердә калдыру, яшь буынга күрсәтү. Әйе, без аны бүген беләбез. Тик яшьләрнең күпчелеге өчен ят бит алар. Безнең менә шул рәвешле буыннар бәйләнешен саклыйсыбыз килә. Районга, шәһәргә кунакка килүчеләр биредә фотога төшәргә ярата. Әгәр шулар арасыннан берничә генә кеше булса да СССРда чыгарылган машиналар белән кызыксынса, максатыбызга ирешкәнбез дигән сүз. Бу автомобильләрнең теле булмаса да, җаны бар төсле безгә.

Кызыксынып китеп, без дә ретро машиналар сата торган сайтларга кереп, әлеге автомобильләрнең кайберләренең бәяләре белән кызыксындык. Билгеле, бәяләр машинаның хәленә, эшләп чыккан елына, узган чакрымнарына карап шактый аерыла. Без исә мисалга берничәне алдык. Мәсәлән, ЗИЛ-157 «Захар» автомобиле өчен 300 мең сум сораучылар бар. 1984 елда чыккан, 100000 чакрым юл узган ИФА-25 машинасын 360 мең сумга табарга мөмкин. Йөрми торган, реставрация өчен яхшы вариант буларак тәкъдим ителә торган 1954 елгы Москвич-401 автомобилен 100 мең сумга тәкъдим итәләр. 1967 елгы Газ-69 автомобилен исә 370 мең сумга сатып алырга мөмкин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 342

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+